Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлегенең Уразай торак пунктында **ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

2018ел, 27 ноябрь №2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Салагыш авыл җирлеге Уразай торак пунктында гражданнар җыены **КАРАР БИРДЕ:**

1. I группа инвалидлар, ялгыз яшәүче өлкән кешеләрдән (80 яшькә җиткән), торып укучы студентлардан тыш, Салагыш авыл җирлегенең Уразай торак пункты территориясендә теркәлгән, шулай ук Салагыш авыл җирлеге Уразай торак пункты территориясендә теркәлмичә яшәүче балигъ булган һәр гражданга 2019 елда үзара салымны 350 сум күләмендә кертергә
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирлектә әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

-су белән тәэмин итү объектларын һәм сууткәргеч челтәрләрне карап тоту.

-җирлек территориясен төзекләндерү.

-урамнарны яктырту.

-кешеләрнең гомере һәм сәламәтлеге иминлегенә яный торган авария хәлендәге һәм коры яшел үсентеләрне кисү.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
муниципаль берәмлек Башлыгы, Совет рәисе М.М. МӨХӘММӘДИЕВ